**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

---

17 ноябрь 2022 ел № 76

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәдәге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлау органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 881 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 82 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарының 1 өлешендәге 3 абзацын (авыл җирле Советының 2018 елның 27 августындагы 93 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 99 номерлы, 2020 елның 26 октябрендәге 11 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) бәян итәргә:

1.1. «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең кече төркеме белгече вазыйфаи окладының күләме 11 958 сум тәшкил итә»;

1.2. «3 нче кушымта «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмен» кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.А. Емельянов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советының
2022 елның 17 ноябрендәге
76 номерлы карарына
3 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата
бүләкләү күләме

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 16390 |